

Урманнарга бай, яшел Мордовия Республикасына сәфәребезне дәвам итеп, 31 майда Атюрьево районы Кыштыру (Большой Шуструй) авылына юл алдык. Борынгы, бай тарихлы авылда безне бик матур каршы алдылар. Һәр белгечебез очен бу очрашу кызыклы, мәгълvматлы булды. Кызганычка каршы, биредә дә мәктәп ябылган. Авыл һәм мәктәп тарихы белән укытучы Совешова Эльвира Хәйдәр кызы таныштырып китте, кайбер материаллар белән дә ярдәм итте.       Чал тарихнын кайбер истәлекләре белән авыл урамыннан узганда да танышып була. Мәсәлән, кайчандыр Мәскәv шәһәрендә дә завод-фабрикалар тоткан, vз авылын гына тvгел, тирә-як авылларны да эшле иткән байларнын йорт, кибет биналары сакланып калган. Кvбесе инде ташландык хәлдә булса да, берсендә әле дә кибет эшләп килә.

1913 елгы чыганаклар буенча авылда 4 мәчет, 5 татар мәктәбе булган. Бvгенге кондә 1 мәчете бар. Гомер буе укытучы булып эшләгән, 39 ел стажлы Теркулов Әхәт Абдрахман улы авылдашлары vтенече буенча мәчеттә алтынчы ел имам вазыйфаларын алып бара. Мәчет караулы, якты, ә ин моһиме, 200 еллык тарихы булган бу мәчетнен шул вакыттагы рәвешен дә саклап калганнар, алай гына тvгел, бинанын тышлык такталарына



да зыян китерелмәгән. Алар анын борынгылыгын, тарихилыгын да, авыл халкынын Аллаһ йортына монәсәбәтен дә кvрсәтеп тора. Совет елларында клуб хезмәтен vтәгән, аннан ашлык склады булып торган мәчетне саклап калуда колхоз рәисе Теркулов Заһидулла Габидуллович (бvгенге кондә вафат) зур коч куйган – бина тозекләндерелеп сафка бастырылган. Бvген исә мәчеткә йорvчеләр дә коннән-кон сирәгәя, авыл картая...

Кыштыру авылы урамнары белән таныштырып, авылдашлары белән очрашуда ярдәм иткән очен китапханәче Чудова Раиса Васильевнага зур рәхмәтебезне белдерәбез. Мукшы милләтеннән булган Раиса ханым шушы авылга килен булып тошеп, татар телен дә ойрәнгән, балаларына да ойрәткән. Ул авыл тарихын да яхшы белә, һәр бина турында озын-озак итеп сойли ала. Авылдашларынын да хормәте зур ана.

Инде бары бер генә урамлы Татар Тенешендә безне укытучы Тактамышева Равилә Шәкvр кызы кабул итте, аларда басма һәм кулъязма китаплар белән дә таныша алдык.

Яна Аллагол авылында исә Хәлилова Рәмзия Әхәт кызы гарәп язуындагы кулъязма дәфтәрне Институтка бvләк итеп тапшырды.
Беренче июньдә Татар Веләзмәсе авылында эш-ләдек. Биредә дә безне vз туганнары кебек каршы алдылар, рәхмәтебез чиксез. Һәр яктан унган халык монда: биилләр дә, жырлыйлар да, тарихтан да мәгълvматлы алар. Тарихи жырлар, авыл койләре дә язып алынды, халыкнын инде онытыла башлаган уеннары, йола-гадәтләре дә искә тошерелде. Татар Веләзмәсе авылында мәчет юк, ләкин хәтемнәр уку очен, жомгаларга йорер очен бер ой биргәннәр. Халык бердәм биредә, алдагы елларда мәчет манарасы кvтәрелеп, азан тавышы янгырар дип ышанып калабыз.



Икенче июньдә Зур һәм Кече Пешләй авылларында булдык. Зур Пешләй авылы мәчетендәге очрашуда безне мәчет имамы Вергасов Заһидулла Каюм улы авылнын 1791 елгы картасы белән таныштырды. Әлеге картанын сакланышы яхшы, язулары да укырлык.  Кайчандыр горләп торган зур авыл инде кечерәеп бара. Янгын афәтләрен дә кvргән авыл – 1937 елда мәчетләре янып колгә әйләнә, сугыштан сонгы елларда ут чыгып, 200 дән артык хужалык янып бетә. 2019 елда исә буш калган мәктәп тә янып юкка чыга. Хәзерге мәчет элекке кибет бинасын янартып кvтәрелгән. Кибет тоту vзен акламый башлагач, бина кvп еллар ташландык хәлдә тора, каты жилдә тvбәсез кала, кар-янгырдан идән-тvшәмнәре бетә бара. Бу хәлне кvреп, Мордовия Республикасы моселманнары Үзәк Диния нәзарәтеннән зур ярдәм итәләр, аннан инде авыл халкы бергәләшеп, акрынлык белән мәчетне сафка бастыралар. Шунысын да әйтергә кирәк, бу эштә руслар да, мукшылар да читтә калмый, алар да vз олешләрен кертә. Шул рәвешле, мәчет кvтәрелә. Ул бvген дә матур гына эшләп килә. Мәчетнен элекке бинасы да фотоларда сакланып калган. Борынгы китапларга да сак караш саклана, без кулъязма китаплар белән дә таныша алдык.
Кече Пешләйдә бvгенге кондә бары 6 гына йорт калган. Ташландык ойләрне кvреп, кvнел сыкрый... Бу авылларда безне озатып йоргән Килдеева Сәимә Али кызы һәм авыл советы житәкчесе Килдеев Сәет Заһидулла улына зур рәхмәтебезне белдерәбез. Алар авыл тарихын яхшы беләләр, авылдашлары белән дә очрашуда зур ярдәм иттеләр.


КУЛЬТУРА-ДЕЛИРИЕ РОССИИ